ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 1 2025 елның 19 ноябре

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Килди авыл җирлегенең Харино торак пунктында 2026 елда гражданнардан
үзара салым кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең Харино торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең Харино торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 100% - СВОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары; 50% - 1 төркем инвалидлар; күпбалалы гаиләләр; көндезге уку йортлары студентлары, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 2026 елда үзара салымны 750 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Килди авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В. М. Бурдин